РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, с.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ Базарлы Матак авылы.
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

424№ 2018 нче елның 29 нчы октябре

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының
2018 елның 31 июлендәге 302 номерлы “Әлки муниципаль
районы территориясендә кешеләрнең
массакүләм җыелу урыннарын тикшерү
буенча ведомствоара комиссия турында”
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы “Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри рәвештә сакланырга тиешле кешеләр һәм объектларның (территорияләрнең) күпләп булу урыннарының террорга каршы яклануына карата таләпләрне һәм мондый урыннар һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспорты формаларын раслау турында" карары таләпләрен үтәү йөзеннән Әлки муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы “Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри рәвештә сакланырга тиешле кешеләр һәм объектларның (территорияләрнең) күпләп булу урыннарының террорга каршы яклануына карата таләпләрне һәм мондый урыннар һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспорты формаларын раслау турында" карарына нигезләнеп төзелгән Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендәге 302 номерлы «Әлки муниципаль районы территориясендә кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында " карарының 4 нче кушымтасын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Объект (территория) хуҗасына Россия Федерациясе Карары белән расланган форма нигезендә куркынычсызлык паспортын эшләүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Әлки муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Йосыпов И.В.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе карарына
4 нче кушымта

_____№ 2018 нче ел «___» _________

## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә кешеләр күпләп була торган урыннарның ИСЕМЛЕГЕ

(Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы “Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри рәвештә сакланырга тиешле кешеләр һәм объектларның (территорияләрнең) күпләп булу урыннарының террорга каршы якланууына карата таләпләрне һәм мондый урыннар һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспорты формаларын раслау турында" карарына нигезләнеп)

| т/б № | Объектның исеме |
|---|---|
| 1 | Базарлы Матак авылының Ленин урамындагы Үзәк паркы |
| 2 | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы бинасы (Крайнов ур., 58 нче йорт) |